Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы
# Мәктәп пульсы



№7
Март
2021 г.

## Международный женский день!




Дорогие, милые дамы, самые очаровательные и непредсказуемые создания, поздравляем вас с Международным женским днём! Желаем вам чудесных дней, наполненных радостными событиями, красивыми словами, любовью и душевностью. Пусть ваши желания исполняются всё чаще, близкие окружают вас теплом и нежностью, заботой и безграничным вниманием. Счастья вам, прекрасные дамы, и пусть оно не заканчивается!

## Туган тел ул - тормыш!

Безнең Арча икенче урта мәктәбендә Туган телләр елы уңаеннан күп чаралар үтте инде. Мин шуларның берничәсен - үзем катнашканнарын гына язып үтәм.

Сыйныфыбыз белән «Әбием сандыгы» дип исемләнгән күргәзмә оештырдык. Чиккән сөлгеләр, җәймәләр, намазлыклар берәүне дә битараф калдырмады: күргәзмә янышнан кеше өзелмәде. Әбиләребез яшь чагында калфак -читекләр, чиккән алъяпкычлардан, билләренә житкән чәчләренә таккан чулпылардан булганнардыр дигән уй кызык тоелды.

«Туган телем ул...» дип исемләнгән акция дә оештырдык. Йөрәк формасында киселгән кәгазьгә туган тел турында фикерләрне яздык. «Туган телем ул- әчәр суым, сулар һавам!», «Туган телем - үткәнем, бүгенгем, киләчәгем», «Туган тел ул - тормыш!» дигән фикерләр күңелемә аеруча хуш килде.

Гыйнвар аеннан башлап, ай саен «Дөньяда сүземез бар - үземез юк (Акмулла)» дип аталган түгәрәк өстәл артында сөйләшү оештырыла.

Гыйнвар аенда юбиляр язучы -шагыйрьләр иҗатына күзәтү ясалды. Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: тел никадәр күбрәк кулланылса, шулкадәр тизрәк үсә, камилләшә бара. Татар халкында киң таралган «Хәрәкәттә - бәрәкәт» дигән мәкальне тел үсешенә карата да кулланып була.

**Эльвина** Хәйретдинова,
9 сыйныф



## Кызыклы фактлар!

**Рун язуы** (VII йөздә барлыкка килә). Азов, Себер, Кавказ, Сент һәм Венгрия җирлекләрендә киң таралган була.

**Уйгур язуы.** Алтын Урда чоры вакытында хан сарайларында рәсми документлар, хатлар язганнар.

**Гарәп язуы.** Татарларга бу язу ислам динен кабул итү белән бергә килә (922). Гарәп язуында күпчелек матбугат язмалары, әдәби әсәрләр язылган.

**Латин язуы.** 1927 елда татарлар латин әлифбасын куллана башлыйлар, ул «Яңалиф» дип атала. Язуда төп принцип - фонетик. Шулай ук бу чорда әлифбага ә, ө, ү, җ, ң, һ хәрефләре кертелә.

**Кириллица.** Татарлар бу әлифбага 1939-1940елларда күчә. Шуннан соң татар халкының язуына үзгәрешләр кергәне юк.

## В этом выпуске:


| | |
|---|---|
| Сила пера | 2 |
| Из жизни школы | 3 |
| Из жизни школы | 4 |
| Из жизни школы | 5 |
| Сугыш хатирәсе | 6 |

# Сила пера

Мы хотим познакомить вас с нашей редколлегией.

Сегодня в редакции школьной газеты работают: редактор, дизайнер-верстальщик, фотокорреспондент, корректор. Каждый сотрудник редакции отвечает за свои обязанности. Редактором нашей газеты является учитель татарского языка и литературы Расима Ибраева. Она занимается проверкой текстов, и редактирует её. Под ее чутким руководством работает вся школьная редакция.

Я являюсь дизайнером-верстальщиком. В мои обязанности входит вёрстка газеты. В отличии от обычного дизайнера я не занимаюсь разработкой макета газеты.




В основном он просматривает газету на наличие грамматических ошибок и исправляет их. Так же он отслеживает правильность написания текстов, условных сокращений и так далее.




Я определяю размер изображений, разбиваю текст на абзацы и подготавливаю проект для печати. Наш фотокорреспондент – Азамат Файзрахманов.

У нас есть корректор – Ислам Габдрахманов. В его обязанности входит нормализация грамматики.

Так же он отслеживает правильность написания текстов, условных сокращений и так далее.

Так же не обойтись без таких программ как: PageMaker, Adobe Photoshop, Microsoft Office Word.

В этих программах работают ребята которые обладают хорошими навыками коммуникации в них. Многие ученики дают нам советы как так или иначе улучшить нашу газету, мы стараемся придерживаться их советов.

Газета выходит на двух языках – Русском и Татарском. Чтобы в точности перевести тот или иной текст на один из языков нам помогают ученики, которые обладают хорошими знаниями в этих областях. Все наши газеты мы публикуем на сайте https://edu.tatar.ru/arsk/sch2. Ученики и учителя могут ознакомится с нашими газетами и в электронном виде.

**Ислам** Сафиуллин,
дизайнер-верстальщик
школьной газеты.

# Из жизни школы



1 марта прошел Республиканский детский художественный фестиваль народного творчества «БЕЗ БЕРГӘ» - это форма выявле-ния одаренных детей.




Поздравляем наших учителей Шакирова Б.Ф. и Нурутдиновау Р.Ф., занявших 3 место в смешанной эстафете в рамках Гвардейского турнира, приуроченного ко Дню защитников Отечества.



4 марта Ученики 4В (руководитель Саляхова Р.Р.) побывали на экскурсии в музее "Заказанье". Его экспозиция представляет историю, культуру, традиции татарского народа на примере признанного центра Заказанья – Арского края.



4 марта в Арской ДШИ состоялся муниципальный этап республиканского детского художественного фестиваля народного творчества «Без бергэ». Наши ученики выступили в номинациях «Вокал» (руководители Мухаметгалиева А.Ф., Саляхова Р.Р.), "Художественное слово" и "Сценическое мастерство" (руководитель Гиниятуллина Г.И.), "Театр мод" и выставка прикладного искусства (руководитель Хайрутдинова Э.Р., Закирзянова Э.Р.)



5 марта в школе прошло чествование победителей и призеров республиканских олимпиад. На чествование присутствовали делегации от классных коллективов школы, в которые вошли лучшие из лучших, ученики, которые учатся только на «хорошо» и «отлично». Они были награждены грамотой, благодарственными письма, памятными подарками и премией от директора.



5 марта во всех классах прошли мероприятия, посвященные Международному женскому дню. Мальчики подготовили подарки и поздравления для своих одноклассниц. Организовали веселые состязания и викторины.



5 марта на классных часах были проведены беседы на тему "Чем богат родной язык". Цель данных занятий заключалась в активизации познавательного интереса обучающихся к языку как к общественному явлению, определение важности изучения родного языка.



В 8 марта наши ученики поздравили вдов ветеранов ВОВ и тружениц тыла. Внимание, особенно в такой добрый весенний праздник, важно каждой женщине!

# Из жизни школы




9 марта в 7х классах прошли мероприятия на тему "Какой язык твой родной?". Ребята рассказывали стихи, исполнили песни на своих родных языках: русском и татарском. В результате мероприятия учащиеся сделали вывод, что нужно беречь свой родной язык и уважать родные языки других людей.



12 марта ученики 4х классов путешествовали по стране ПДД. Ребята показали свои знания ПДД, рассказали, зачем на дорогах нужен светофор, как нужно вести себя в общественном транспорте, рассказывали стихи по ПДД и т.д. Перед учениками выступила агитбригада отряда ЮИД нашей школы.



8 марта Юнармейцы нашей школы оказывают помощь маме Марата Лотфуллина.



13 марта прошёл "Фестиваль народных сказок", посвященное Году родных языков, которую провели ученики 6Б класса. Ребята познакомили учащихся со сказками разных народов мира: татарской, удмуртской, болгарской, таджикской, чеченской, азербайджанской.



13 марта состоялась премьера спектакля по пьесе С Я. Маршака " Двенадцать месяцев". Спектакль представили ученики 6Б класса (кл.руководитель Гиниятуллина Г.И.)




Ученица 4 класса Тумакова В. заняла 3 место в конкурсе на лучшее исполнение ганона "Ручеек", который проходил в Арской школе искусств.



14 марта в Атнинском районе прошел II открытый турнир Атнинского района по традиционному каратэ. Наши ученики заняли призовые места: Хакимов Р., ученик 2 класса, занял 2 место в индивидуальной ката (2013-2012г.р.); Зайнуллин М., ученик 5 класса, занял 3 место в индивидуальной ката (2008-2009г.р.)



19-20 марта в Казани проводилось Первенство Спортивной Школы единоборств «Ак Буре» по таэквон-до среди юношей и девушек 2007-2009 г.р. и мальчиков и девочек 2010 г.р., которое собрало более 150 спортсменов Республики Татарстан. Среди Арских спортсменов были и наши ученики, которые выступили в этих соревнованиях и привезли две золотые (Габдрахманов Ислам, Хайрутдинова Камиля), серебряную (Гарифуллин Камиль) и две бронзовые медали (Хамраев Шамиль, Хабибуллин Амир), участие Галимов Амирхан.

# Из жизни школы




19 марта Гатауллина Л., ученица 10 класса нашей школы, провела интеллектуальную игру "Где коррупция?" в АСОШ#6. Игра была проведена в рамках республиканского конкурса на должность молодежного помощника главы муниципального района по противодействию коррупции.



В дни весенних каникул было проведено большое количество спортивных соревнований в которых активное участие приняли наши ученики и заняли призовые места: Первенство Арского района по корэш среди юношей 2008гр; Первенство Арского района по плаванию среди юношей и девушек 2004-2009 гр; Первенство Арского района по лыжным гонкам. Спринт; Первенство Арского района по бадминтону; 3е открытое Первенство Нижегородской области по традиционному каратэ.




22 марта команда учителей нашей школы по волейболу заняла 1 место в зональных соревнованиях среди членов профсоюза учреждений образования Арского муниципального района РТ.



24 марта прошло награждение призеров и победителей муниципального этапа республиканского конкурса "Без бергэ".



19 марта в рамках акции РДШ "День Счастья" в школе работала "Почта радости". На "Дереве счастья" ученики разместили свои записки с пожеланиями, а участники акции разносят полученные записки по школе. В результате акции ученики и учителя получили записки с самыми добрыми пожеланиями, что безусловно подняло настроение всем.



20 марта наши ученики стали участниками праздника Навруз. Весенний новогодний праздник равноденствия —Навруз, зародившись более 3000 лет назад, почти одновременно с возникновением земледелия, распространился по многим странам. В настоящее время отмечается в дни, на которые приходится весеннее равноденствие.



24 марта во Дворце школьников прошли соревнования по шахматам "Лучший шахматист".Демухаметов А., ученик 10 класса, занял 2 место.



26 марта наши ученики побывали на встрече с молодой поэтессой Олесей Феоктистовой.

# Сугыш хатирәсе

Мәчет тавындагы мәктәп тәрәзәсеннән офык читен, басу түрендәге жыелып теземнәргә салынган алтынсу төстәге салам чүмәләләрен күзәтергә ярата Сания. Әйтерсең, анда аның кабатланмас балачак еллары, яшьлеге. Их, ул кахәрле балачак! Гаилә белән Донбасста яшәгән сугыш еллары...

1941 нче елны әтисе Шәйми абыйның сугышка киткәндә көрәктәй зур кулларына күтәреп: “Кызым, үскәч укытучы бул яме, киңәшемне онытма! Әниеңнең сүзеннән чыкмагыз!” – дигән сүзләрен бүген дә хәтерли әле ул. Әгәр әтисе белән башка күрешмәячәкләрен белгән булсамы?..

1942 нче елны әнисе Гөлчирә апа бишенче баласын тудыргач, нәни Илсурны кулына алып: “Ничекләр туендырырмын? Ярдәмеңнән ташлама, Аллаһ Тәгаләм!”, - дип ялварды.

Алар яшәгән авылны немецлар чолгап алды. Саниягә ул вакытта сигез яшь иде. Карт-коры, хатын-кыз, балаларны, вагонга төяп, Германиягә озатыр өчен, якындагы станциягә жәяүләп кудылар.

Февральнең зәмһәрир салкыны. Иңендәге бер кат иске калын шәленең шакмакларына кадәр тонык зәңгәр төстә икәне хәтердә. Бара алмыйча егылганнарны фашист автоматы сагалап кына тора. Авыру, хәлсез әби-бабайлардан юлга чыккач та котылу жаен гына эзли немец солдаты. Ул хәшәрәтләрне әти-әни үстермәгән диярсең. Ачлыктан, суыктан үлеп калучылар да байтак. Илсурын тапканнан соң хәлсезләнеп калган әнисе, кулындагы яңа туган улын алып бара алмагач, якындагы чокырга ташлады. Немец абайламый калдымы, әллә күрмәгәнгә салышты, халыкны ары кууын белде. Чарасызлыктан йөрәге телгәләнгән ана һаман артына әйләнеп карый. Кирегә чабарга талпына. Янәшәсендә барган дүрт сабыен кызганып тагын юлын дәвам итә. Атлаган саен күз яшьләренә буылып сөртенә. Бар гайрәтен, көчен жыеп өстерәлеп дигәндәй бара. Сөт төшкән күкрәге сызлауданмы, күңеле әрнүдәнме ыңгырашып куя. Әнисенең күз карашы: “Кызым, энеңне ташлама, жаен табып кал янында!” – ди кебек. Мине аңлыйсыңдыр, балам, дигәндәй әледән-әле олы кызына карап алса да, теле белән әйтергә кыюлыгы житми. Хәер, сөйләшкәнне күрсә, немец күп уйлап тормый, автомат түтәсе белән генә тондыра. Аңламыймы соң Сания, барын да аңлый.

Үзе дә сабый гына булган кызчык, Аллаһының хикмәте беләндер, төркемнән артта калып, энесе яткан чокырга чаба. Барыбер исән калмас, ачлыктан яки суыктан катып үләр диепме, әллә чыннан да сизми калыпмы, аны туктатучы булмый.

Авылны чыгып, берничә чакрым узгач, немецлар ял итеп алырга ниятли. Гөлчирә апа туктаган урында салам чүмәләсе туры килә. Жай чыгу белән, янындагы сабыйларын шул чүмәләгә күмә.

Коточкыч әсирлектән, үлемнән котылып калу жае чыгуны Аллаһ Тәгаләнең кодрәте дими ни дисең? Немец солдатлары әсирләрне бу жирдән куалап алып китәләр. Караңгы төшкәч, Гөлчирә апа салам чүмәләсе эченнән чыгып, балалары белән көч-хәл кире кайта. Кайтышлый күпме генә эзләсәләр дә, Илсур белән Санияне таба алмыйлар. Өенә хәлсезләнеп кайтып кергәндә, нәни энесен кочаклап елый-елый шешенеп беткән кызын күреп, чак аңын жуймый ана.

Сугыш елларында салам чүмәләсе менә шулай аларны үлемнән алып калды. Шуңа ярата Сания басу түрендәге әлеге теземнәрне. Әнә бит, зәңгәр төшкән тау итәгендәге каеннар да алтынсу шәленә төренеп тынып калган. Ә таудан менүгә киң басу, кунак көткәндәй, сабыр гына көзне каршылый.

Әтисенең теләге кабул булды. Сания - 32 ел мәктәптә укытучы. Жай чыкканда, сугыш хатирәсен укучыларына, оныкларына сөйли. Нинди бәхетле балачак илендә яшәгәннәрен, тынычлыкның, рәхәт тормышның кадерен белсеннәр дип сөйли ул. Ә гыйбрәт алырдай сугыш хатирәләре күп әле Сания апаның күңел сандыгында. Аларны тыңлаган бер генә сабый да шәфкатьсез, кешелексез, тәрбиясез булмас.

**Рәсимә** Ибраева, татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**Редактор** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Ислам Сафиуллин
***Фотокорреспондент*** Азамат Файзрахманов
***Корректор*** Ислам Габдрахманов
***Редколлегия*** Камиль Гарифуллин
Раниль Заляев

***Адрес:*** ул. Мостовая, дом 15

***Сайт школы*** https://edu.tatar.ru/arsk/sch2